**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«01» 04 2021 ел Яр Чаллы № 998

Башкарма комитетның 2020 елның 10 мартындагы «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне кайтару максатында, оешмаларга Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 741 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 10 мартындагы 741 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне кайтару максатында, оешмаларга Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе»нә түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

1.1. 8 пунктны: «Башкарма комитет субсидия алучының субсидия алу турында гаризасын кергән көнне терки һәм аны теркәгәннән соң ун эш көне эчендә документларның әлеге тәртип таләпләренә туры килүен тикшерә.

Алучы әлеге Тәртипнең 2 һәм 5 пунктлары шартларына туры килүне тәэмин иткәндә, Башкарма комитет субсидия бирү турында комиссия карары кабул итә.

Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Карар катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.».

9 пунктны: «Субсидия бирү өчен нигез булып субсидия бирү мөмкинлеге турында карар тора».

10 пунктны: «Субсидияләр Тукай муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан оешмаларның кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына күчерелә. Субсидияләрне күчерү срогы – Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң кимендә 10 эш көнендә».

1.2. Әлеге Тәртипкә «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне кайтару максатында, оешмаларга Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча комиссия составы» дигән 1 кушымтаны өстәргә.

2. «Башкарма комитетның 2020 елның 10 мартындагы «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне кайтару максатында, оешмаларга Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 741 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Башкарма комитетның 2020 елның 8 маендагы 1625 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районы сайтында (tukay.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 01 04 998 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне кайтару максатында, оешмаларга Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Хәбибуллин А.Р. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе – комиссия рәисе |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Заһретдинов Ф.С. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Игътисамов Р.С. | Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү буенча урынбасары |
| Мәрдәнова Э.В. | Финанс-бюджет палатасы рәисе вазыйфаларын башкаручы |
| Халитова Э.А. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы |
| Бузина Н.К. | Тукай муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы |
| Мадярова Д.Ә. | Төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге баш белгече |
| Дудникова Е.А. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |
| Камалова А.Р. | Финанс-бюджет палатасының әйдәп баручы белгече. |